ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

13 октябрь, 2023 ел. Яңа поселогы №1

“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Яңа Сарайлы авылында үзара салым акчаларын керту һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештырунның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Уставы,

КАРАР БИРӘМ:

1. 26 октябрь көнне 2023 елның сәгать 16.00 Яңа Сарайлы авылында үзара салым керту мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Яңа Сарайлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, күп балалы гаиләләр һәм студентлар өчен бер тапкыр түләүне киметергә риза буласызмы? 500 (биш йөз) сум күләмендә әлеге категория гражданнар өчен билгеләргә, алардан суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк:

-электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

-гаилә ялы өчен мәйданчык төзу (балалар уен элементлары, эскәмияләр, урам фонарлары сатып алу);

-авыл мәдәният йортын ремонтлау

"КАРШЫ" “РИЗА”

3. Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Яңа Сарайлы авылы, Үзәк урамы, 51А йорт адресы буенча үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

5. Әлеге карарны мәгълүмәт стендларында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар аның игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Г.Т.Хусаинова